**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШЛЫГЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.10.2023 **Чирмешән авылы** №118

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Ульяновка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында**

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясына таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2023 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2021 елның 22 декабрендәге №80 карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында ачык тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә **КАРАР ИТӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Ульяновка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча кушымталар (Том №1, том №2, шәһәр төзелеше зоналаштыруның график карталары: Территориядән файдалануның аерым шартлары булган зоналар, Территориаль зоналар) нигезендә ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

- ачык тыңлауларны оештыручы - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты;

- ачык тыңлауларны үткәрү вакыты - 2023 елның 8 ноябрендә 15.00 сәгатьтә.

- үткәрү урыны – түбәндәге адрес буенча урнашкан Ульяновка авыл җирлегенең авыл мәдәният йорты: Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Ульяновка авыл җирлеге, Ульяновка авылы, Үзәк урамы, 48 йорт.

- тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә ала торган адрес - Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Ульяновка авылы, Үзәк урамы, 44 йорт, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге башкарма комитеты.

3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү, ачык тыңлаулар үткәрү буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Эшче төркем рәисе - Җамалетдинов Илнур Минсәгыйт улы, Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;

Эшче төркем рәисе урынбасары - Вилданов Муса Габделхак улы, Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары;

Эшче төркем әгъзалары:

Севастьянова Наталья Николаевна - Чирмешән муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе;

Җиһаншина Эльвира Бурундай кызы - Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы;

Шәмсетдинов Самат Зәки улы - Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге башлыгы;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 2023 елның 24 октябреннән да соңга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Советы рәисе Р.Т. Айбатов